БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 14 » ноябрь 2018 ел № 337

«2015 - 2020 елларга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

«2015-2020 елларга Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 10 сентябрендәге 763 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2014 елның 13 ноябрендәге 347 номерлы карары белән (2015 елның 18 декабрендәге 481 номерлы, 2016 елның 23 маендагы 136 номерлы, 2017 елның 15 декабрендәге 274 номерлы, 2018 елның 31 августындагы 284 номерлы үзгәрешләр белән) расланган «2015-2020 елларга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасына (алга таба - муниципаль программа) кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар аңа имза куйган көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче урынбасары И.С Галимуллин